УПРАВЛЕНИЕ ЗАГС
КАБИНЕТА МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Улица Ахтямова, дом 14,
город Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ
ГХАТ ИДАРӘСЕ
Әхтәмов урамы, 14 нче йорт,
Казан шәһәре, 420021

Тел./ факс: (843) 293-14-89, zags@tatar.ru, zags.tatarstan.ru

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**Казан ш.**

**«29» октябрь, 2019 ел.** **№ 82**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсенең 2013 елның 17 декабрендәге 144 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе тарафыннан апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсенең (алга таба – Идарә) «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе тарафыннан апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 17 декабрендәге 144 номерлы боерыгы (Идарәнең 2016 елның 28 сентябрендәге 62 номерлы, 2018 елның 19 июнендәге 35 номерлы, 2018 елның 24 октябрендәге 85 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе тарафыннан апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Регламент), аны кушымтада бирелгән яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

2. Идарәнең документлар формалаштыру, исәпкә алу, саклау һәм бирү бүлегенә тайпылмыйча Регламент нигезләмәләренә таянып эш итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Идарә җитәкчесе Г.Р.Нигъмәтуллина

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсенең 2013 елның 17 декбарендәге 144 номерлы боерыгы (2019 елның 29 октябрендәге 82 номерлы боерык редакциясендә) белән расланды

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе тарафыннан апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Административ регламент (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе (алга таба – Идарә) тарафыннан гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга вәкаләтле органнар тарафыннан бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турындагы документларга апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Гариза бирүчеләр: дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән физик затлар.

1.3. Дәүләт хезмәте Идарә тарафыннан күрсәтелә. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларны документлар формалаштыру, исәпкә алу, саклау һәм бирү бүлеге (алга таба – Бүлек) белгечләре гамәлгә ашыра.

1.3.1. Идарә урнашкан урын: 420021, Казан ш., Әхтәмов ур., 14 й.

Идарәнең эш графигы:

Дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр.

Җомга 9.00 сәгатьтән 16.45 сәгатькә кадәр.

Төшке аш 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Гаризалар кабул итү графигы:

Дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе 9.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр.

Җомга 9.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр.

Төшке аш 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Керү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.

1.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм аны үтәү барышы турында мәгълүмат Бүлек тарафыннан әлеге телефон аша бирелә: (843) 293-33-47.

1.3.3 «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составына керүче Идарәнең рәсми сайты адресы (алга таба – «Интернет» челтәре һәм Идарәнең рәсми сайты): http://zags.tatarstan.ru, электрон почта адресы: zags@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) Идарә бинасында урнашкан дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

Идарәнең рәсми сайтында (http://zags.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi. tatarstan.ru);

3) Идарәгә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон буенча);

4) Идарәгә язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.5 Идарәнең урнашу урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, шулай ук Идарәнең электрон почта адресы турында мәгълүмат Идарәнең рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырыла.

Идарә бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында дәүләт хезмәте турында әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге мәгълүматлар урнаштырыла.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Конституциясе (Российская газета, 1993, 25 декабрь, кертелгән төзәтмәләрен исәпкә алып);

Чит илнең рәсми документларын легальләштерү таләбен гамәлдән чыгара торган конвенция (Гаагада 1961 елның 05 октябрендә төзелгән) (Россия өчен 1992 елның 31 маенда үз көченә кергән) (Чит илнең рәсми документларын легальләштерү таләбен гамәлдән чыгара торган Конвенция статусы белән берлектә (2006 елның 16 гыйнварына) (алга таба – Гаага конвенциясе) (Халыкара шартнамәләр бюллетене, 1993, №6; «Вестник Высшего Арбитражного Суда Российской Федерации», 1996, №12);

Россия Федерациясе Салым кодексы (икенче кисәк) (алга таба – РФ Салым кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2000, №32, 3340 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Гражданлык хәле актлары турында» 1997 елның 15 ноябрендәге 143-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 143-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1997, №47, 5340 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, №31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясе территориясеннән чыгарылырга тиешле Россия рәсми документларына апостиль кую турында» 2015 елның 28 ноябрендәге 330-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 330-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 30.11.2015, №48 (1 кисәк), 6696 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы указы (алга таба – 601 номерлы указ) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, №19, 2338 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә апостиль куюга вәкаләтле компетентлы органнар турында» 2016 елның 30 маендагы 479 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016, №23, 3326 ст.);

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының «Россия Федерациясе субъекты (субъектлары) буенча Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы идарәсе турында нигезләмә һәм Россия Федерациясе субъектлары буенча Юстиция министрлыгы идарәләре исемлеген раслау турында» 2014 елның 3 мартындагы 26 номерлы боерыгы (алга таба – РФ субъекты (субъектлары) буенча РФ Юстиция министрлыгы идарәсе турында нигезләмә) (Российская газета, 2014, 26 март, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Конституциясе (Республика Татарстан, 2002, 30 апрель, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе мәсьәләләре» 2007 елның 07 ноябрендәге 614 номерлы карары (алга таба – Идарә турында нигезләмә) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы, 2007, №42, 1674 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – 880 номерлы карар) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 2010, №46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

апостиль – имзаның чын булуын, документка кул куйган затның кем сыйфатында катнашканлыгын һәм, тиешле очракта, әлеге документта беркетелгән мөһернең яки штампның чын булуын таныклый торган махсус штамп;

йолдызчык – мөһер куелып, документларның битләре тоташтырылган урында ябыштырыла торган тыгыз кәгазь;

техник хата – Идарә тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу хатасы, басма хата, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәре яки муниципаль районы (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе бозылуга шикаять (алга таба – шикаять) – гариза бирүченең яки аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәтен күрсәтә торган орган яки аның хезмәткәрләре тарафыннан әлеге гариза бирүченең дәүләт хезмәтеннән файдаланганда бозылган хокукларын яки законлы мәнфәгатьләрен торгызу яки яклау турында таләп итүе.

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәтеннән файдалану турындагы мөрәҗәгать аңлашыла (210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пункты). Гаризаның тәкъдим ителгән формасы әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына булган таләпнең атамасы | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең атылышы | Татарстан Республикасында гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга вәкаләтле органнар тарафыннан бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турындагы документларга апостиль кую | Гаага конвенциясенең 5 статьясы;<br>143-ФЗ номерлы федераль законның 13 статьясы;<br>Идарә турында нигезләмә |
| 2.2. Башкарма хакимият органы исеме | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе (алга таба – Идарә) | Идарә турында нигезләмәләрнең 3.3.23 п. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Татарстан Республикасында гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга вәкаләтле органнар тарафыннан бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турындагы документларга апостиль кую яки апостиль куюдан баш тарту турында хәбәр итү<br>Апостиль турыдан-туры документның текст булмаган өлешендә яки аның икенче ягында, йә аерым кәгазь битендә куела (1 нче кушымта). Бу очракта документ битләре һәм апостиль куелган бит теләсә нинди төстәге җеп белән тегү юлы белән, беркетеп куела һәм саннар сугыла. Беркетелгән урында документларның соңгы бите тыгыз «йолдызчык» кәгазе белән ябыштырыла, аңа мөһер куела. Мөһер «йолдызчык»та тигез урнашырга тиеш. Беркетелгән кәгазьләрнең саны апостиль куйган затның имзасы белән таныклана. | Гаага конвенциясенең 4 статьясы. |

| | | |
|---|---|---|
| | Апостильдә документка кул куйган затның фамилиясе һәм инициаллары, вазыйфасы, документ биргән оешманың рәсми исеме күрсәтелә, урыны (шәһәр), датасы, затның фамилиясе, инициаллары, таныклый торган органның исеме, апостильнең номеры күрсәтелә, таныклый торган затның имзасы һәм мөһере белән беркетелә | |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты | Шәхсән мөрәҗәгать иткәндә – гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне.<br>Документлар почта аша җибәрелгән очракта – документлары теркәлгән гариза алынган көнне.<br>Гариза бирүче тарафыннан дәүләт пошлинасын түләү вакыты дәүләт хезмәте күрсәтү вакытына керми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын түләү турында ведомствоара мөрәҗәгать формалаштыру һәм җибәрү кирәк булган очракта – дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза кергән көннән алып иң күбе биш эш көне.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктату өчен нигезләр юк | 330-ФЗ номерлы федераль законның 6 статьясы.<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7.2 статьясының 3 пункты |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | Апостиль кую буенча дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бирүчегә түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:<br>гариза (2 нче кушымта);<br>шәхесне таныклый торган документ (күрсәтелә).<br>Гражданлык хәле актын дәүләт теркәвенә алу турында Татарстан Республикасында гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга вәкаләтле җирле үзидарә органнарыннан (алга таба – ГХАТ органнары) яки Идарәдән чыккан документ (туу, өйләнешү, аерылышу, вафат булу турында, аталыкны билгеләү, уллыкка алу | Гаага конвенциясенең 4, 5 статьялары;<br>143-ФЗ номерлы федераль законның 13 статьясының 2 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | турында, исем алмаштыру турындагы таныклыкларның (белешмәләрнең), гражданлык хәле акты язуының булмавы турында белешмәнең төп нөсхәсе).<br>Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын гариза бирүче Идарәгә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Идарәнең рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе ярдәмендә кәгазьдә тапшырылырга (җибәрелергә) тиеш:<br>шәхсән;<br>почта юлламасы белән.<br>Гариза һәм кушымта итеп бирелә торган документлар электрон формада тапшырылмый | |
| 2.6. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе; шушы документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма. | Түләүче зат тарафыннан дәүләт пошлинасын түләү фактын раслый торган белешмәләр (Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсе).<br>Дәүләт пошлинасын түләү фактын раслый торган документларны гариза бирүче үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы.<br>Югарыда күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документларның гариза бирүче тарафыннан тапшырылмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Гариза бирүче тапшрырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм аларны тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.<br>Гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру | 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 2 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документ(лар)ның тапшырылмавы.<br>2. Апостиль кую өчен тапшырылган документ гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга вәкаләтле җирле үзидарә органы яисә Россия Федерациясенең башка субъекты территориясендә гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлеген оештыруга компетенцияле башкарма | |

| | | |
|---|---|---|
| | хакимият органы тарафыннан бирелгән булса.<br>3. Гражданлык хәле актын теркәү турында гариза бирүче тарафыннан тапшырылган, апостиль куелырга тиешле документта төзәтүләр, өстәп язылган, чистартылган урыннар булса, ГХАТ органының герблы мөһер тамгасын укып булмаса | |
| 2.8. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>1. Вазыйфаи затның имзасы һәм (яки) ГХАТ органы куйган мөһер тамгасы Идарәдә булган үрнәкләргә туры килмәгән очракта.<br>2. Әгәр әлеге гаилә таркалган булса, өйләнешү турында таныклык тапшырылган очракта.<br>3. Гражданлык хәле актын теркәү турында тапшырылган документның эчтәлеге гражданлык хәле акты эчтәлегенә туры килмәгән очракта.<br>4. Гариза бирүче тарафыннан Россия Федерациясе Салым кодексының 333.33 статьясының 1 пунктындагы 48 пунктчасында билгеләнгән күләмдә дәүләт пошлинасы түләнмәгән очракта. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм аны алу нигезләре | Бер документта апостиль куйган өчен 2500 сум күләмендә дәүләт пошлинасы түләнә.<br>Апостиль куюны сорап мөрәҗәгать иткәндә түли торган зат (апостиль куйдыру өчен мөрәҗәгать иткән физик зат) дәүләт пошлинасын апостиль куелганчы түли.<br>Дәүләт пошлинасын түләү түбәндәге реквизитлар буенча башкарыла:<br>Түләү алучының исеме:<br>Татарстан Республикасы буенча Федераль | РФ Салым кодексының 333.33 статьясының 1 пунктындагы 48 пунктчасы;<br>РФ Салым кодексының 333.17 статьясы;<br>РФ Салым кодексының 333.18 статьясының 1 пунктындагы 5 пунктчасы, |

| | | |
|---|---|---|
| | казначылык идарәсе (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы идарәсе).<br>Түләү алучының реквизитлары:<br>Бүлекчә – Татарстан Республикасы Милли банкы<br>БИК 049205001<br>ИНН 1659084702<br>КПП 166001001<br>ОКТМО 92701000<br>Р/с 40101810800000010001<br>КБК 31810805000010002110<br>Советлар Союзы Геройлары, Россия Федерациясе Геройлары һәм Дан орденының тулы кавалерлары, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары дәүләт пошлинасын түләүдән азат ителә.<br>Россия Федерациясенең халыкара килешүләре нигезендә сорала торган, шулай ук Россия Федерациясе дипломатия вәкиллекләре һәм консуллык учреждениеләре мөрәҗәгатьләре буенча гражданлык хәле актларын теркәү турындагы документларга апостиль куйган өчен дәүләт пошлинасы түләнми. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен башка түләү алынмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән, Идарә һәм (яки) вазыйфаи зат гаебе белән җибәрелгән хаталарны төзәтү өчен җибәрелгән документка үзгәрешләр керткән очракта, гариза бирүчедән түләү алынмый | 3 пункты;<br>1 пунктның 10, 11, 12 пунктчалары,<br>РФ Салым кодексының 333.35 статьясының 3 пунктындагы 12 пунктчасы |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| документ (документлар) турында белешмәләр | | |
| 2.11. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры | Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы затны (гариза бирүчене) кабул итүне (хезмәт күрсәтелүне) көтү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында гариза бирүченең гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне – Гаризаларны теркәү журналында өч минут эчендә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгына каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү) мөмкинлеге тудырыла. | 880 номерлы карар |

| | | |
|---|---|---|
| стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турындагы визуаль һәм текстлы мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы булган урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыт озынлыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, гариза бирүченең ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган | Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең һәркем өчен мөмкинлекле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>Идарә биналарының җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Идарәнең рәсми сайтында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;<br>документларны кабул итү, тапшыру эшләре башкарыла торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган каршылыкларны җиңүдә ярдәм | |

| | | |
|---|---|---|
| күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтен һәм (яки) муниципаль хезмәтне алу турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган гариза тапшыру (комплексля гарызнамә) юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтен алу (шул исәптән тулы күләмдә) яки ала алмау мөмкинлеге | күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>Идарә белгечләре тарафыннан Регламент бозылуга карата прецендентлар (нигезле шикаятьләр) булуы.<br>Гариза бирүченең Идарә белгечләре белән бәйләнешкә керү күләме:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны тапшырганда, турыдан-туры – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гариза бирүченең Идарә белгече белән бер мәртәбә хезмәттәшлек итүенең вакыт озынлыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннары аша дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гариза тапшыруны да кертеп, дәүләт хезмәте дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турындагы мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Идарәгә мөрәҗәгать иткән очракта алынырга мөмкин.<br>Экстерриториаль принцип һәм комплекслы мөрәҗәгать буенча дәүләт хезмәте күрсәтелми. | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен | Гариза бирүче тарафыннан консультация вазыйфаи затка шәхсән мөрәҗәгать итү формасында, телефон буенча һәм (яки) электрон почта (шул исәптән | |

| | | |
|---|---|---|
| исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | e-mail: zags@tatar.ru электрон почтасы) аша, Татарстан Республкасы порталындагы рәсми интернет-кабул итү (http://zags.tatarstan.ru) системасы аша алынырга мөмкин.<br>Гариза һәм кушымта итеп бирелә торган документлар электрон формада тапшырылмый. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау.

3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле гаризаны рәсмиләштерү өлешендә дә;

гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын түләү турында ведомствоара мөрәҗәгать формалаштыру һәм җибәрү;

апостиль кую яки апостиль куюдан баш тарту;

гариза бирүчегә документларны бирү яки җибәрү;

техник хаталарны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле гаризаны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.2.1. Гариза бирүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультация алу мәсьәләсендә Идарәнең документлар формалаштыру, исәпкә алу, саклау һәм бирү бүлегенә (алга таба – Бүлек) вазыйфаи затка шәхсән телдән мөрәҗәгать итү формасында, телефон һәм (яки) электрон почта (шул исәптән e-mail: zags@tatar.ru электрон почтасы), Татарстан Республикасы Порталындагы интернет-кабул итү системасы аша мөрҗәгать итә ала.

Бүлек җитәкчесе гариза бирүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча да, консультацияләр бирә һәм, кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле гаризаны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә:

Бүлек җитәкчесе, документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 п. каралган нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Искәрмәләр булмаган очракта, Бүлек җитәкчесе гаризаны кабул итә һәм Гаризаларны теркәү журналында терки (3 нче кушымта).

Әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булган очракта, Бүлек җитәкчесе гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булуы турында хәбәр итә һәм, документларны кире кайтару сәбәпләрен аңлатып, аңа документларны кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне өч минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гаризаларны теркәү журналындагы теркәү язуы яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.1.1. Тапшырылган документларны тикшергәннән соң Бүлек җитәкчесе, әгәр гариза бирүче дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен дәүләт пошлинасы түләнгәнлеген раслый торган документларны үз ихтыяры белән тапшырмаган булса, программа-техник чаралардан файдаланып рәсми мөрәҗәгать формалаштыра һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә аны электрон формада җибәрә:

Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенә – дәүләт хезмәте күрсәткән өчен гариза бирүче тарафыннан дәүләт пошлинасын түләү турында мәгълүмат бирү хакында.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: электрон формада җибәрелгән ведомствоара рәсми мөрәҗәгать.

3.3.1.2. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек аша кергән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә белешмәләр белән тәэмин итүче затлар тарафыннан соратып алына торган документлар (мәгълүмат) бирелә яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында хәбәр (алга таба – кирәкле документларның (мәгълүматның) булмавы турында хәбәр) җибәрелә.

3.3.1.3. Бүлек җитәкчесе әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган, шулай ук ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша алынган белешмәләр яки гариза бирүче тарафыннан үз ихтыяры белән тапшырылган документлар нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә:

гражданлык хәле актын дәүләт теркәвенә алу турындагы документка апостиль кую турында яки апостиль куюдан баш тарту турында карар кабул итә һәм гариза бирүчегә, гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, кабул ителгән карар турында хәбәр итә;

әлеге Регламентның 2.3 пункты нигезендә документка яки аерым кәгазь битенә «апостиль» штампын куя яки апостиль куюдан баш тарту турында хәбәр әзерли;

апостиль куелган документны апостиль куюны исәпкә алу реестрында терки (4 нче кушымта) яки гаризаларны теркәү журналына апостиль куюдан баш тарту турында хәбәр реквизитларын кертә (3 нче кушымта);

гариза бирүчегә апостиль куелган документны яки, апостиль куюдан баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, апостиль куюдан баш тарту турында хәбәр тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

гариза бирүче дәүләт пошлинасын түләү турында раслый торган документларны үз ихтыяры белән тапшырган очракта – гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне 15 минут эчендә;

ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү кысаларында белешмәләр алынганнан соң – гариза бирүче килгән көнне чират тәртибендә, 15 минут эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган апостиль куелган документ яки апостиль куюдан баш тарту турында хәбәр.

3.3.2. Почта аша гариза биргәндә дәүләт хезмәте күрсәтү:

3.3.2.1. Бүлекнең корреспонденцияне теркәү өчен җаваплы белгече (алга таба – Бүлек белгече), гариза һәм документлар килгән очракта:

гаризаны һәм документларны кабул итә;

гаризаны Гаризаларны теркәү журналында (электрон рәвештә) терки;

гаризаны һәм документларны Бүлек җитәкчесенә карау өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар килгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Бүлек җитәкчесенә җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.2.2. Бүлек җитәкчесе:

әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булу-булмавына, шулай ук әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре булу-булмавына карата тапшырылган документларны тикшерә;

әлеге Регламентның 2.3 пункты нигезендә документка яки аерым кәгазь битенә «апостиль» штампын куя;

документны апостильләр реестрында терки (4 нче кушымта).

Әгәр гариза бирүчедән дәүләт пошлинасының түләнгән булуын раслый торган документлар алынмаса, әлеге Регламентның 3.3.1.1 һәм 3.3.1.2 пунктчаларында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезе булган очракта, Бүлек җитәкчесе, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерү әзерли.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

гариза бирүче дәүләт пошлинасын түләү турында раслый торган документларны үз ихтыяры белән тапшырган очракта – гариза һәм документлар алынган көнне;

ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү кысаларында белешмәләр алынганнан соң – рәсми мөрәҗәгатькә җавап алынган көнне.

Процедураларның нәтиҗәсе: апостиль куелган документ яки апостиль куюдан баш тарту турында хәбәр.

3.3.2.3. Бүлек белгече:

заказлы хат белән гариза бирүче тарафыннан күрсәтелгән адрес буенча апостиль куелган документны яки, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, апостиль куюдан баш тарту турында хәбәр җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамланган көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: апостиль куелган документ яки апостиль куюдан баш тарту турында гариза бирүче адресына җибәрелгән хәбәр.

3.4. Техник хаталарны төзәтү.

3.4.1. Апостильне яңадан рәсмиләштерү элегрәк куелган һәм гариза бирүчегә тапшырылган апостильдә җибәрелгән техник хаталарны (язу хаталарын, басма хаталарны, грамматик яки арифметик хаталарны) бетерүгә бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла. Бу очракта гариза бирүче түбәндәге документларны тапшыра:

техник хатаны (язу хаталарын, басма хаталарны, грамматик яки арифметик хаталарны) төзәтү турында гариза (5нче кушымта);

гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы (язу хаталары, басма хаталары, грамматик яки арифметик хаталары) булган документ.

3.4.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә киткән техник хатаны (язу, басма хаталарын, грамматик яки арифметик хаталарны) төзәтү турындагы гариза гариза бирүче тарафыннан шәхсән тапшырыла яки почта аша хат итеп җибәрелә.

Апостильне яңадан рәсмиләштерү әлеге Регламентның 3.3 пункты нигезендә, гариза бирүче тарафыннан дәүләт пошлинасын түләмичә генә гамәлгә ашырыла.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Идарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан Регламент һәм дәүләт хезмәтен үтәүгә карата таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актларның нигезләмәләре үтәлүенә һәм башкарылуына карата, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүгә карата агымдагы контрольлек Идарә җитәкчесе урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.2 Агымдагы контрольлек Идарә вазыйфаи затларының Регламентта һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контрольлек даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору, гариза тапшыручыларның хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерү, карарлар кабул итү һәм гариза бирүчеләрнең Идарә вазыйфаи затлары карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән мөрәҗәгатьләренә җаваплар әзерләү.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү Идарә актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тикшерүләр планлы (Идарәнең эш планы нигезендә гамәлгә ашырыла торган) һәм планнан тыш булырга мөмкин.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) Регламенттагы һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) физик затлар Идарәнең дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавы) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә, анда ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны юкка чыгару буенча тәкъдимнәр теркәлә.

4.7. Контрольлек нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар тарафыннан контрольдә тоту Идарәгә мөрәҗәгатьләр җибәрү юлы белән, шулай ук Регламентны үтәү барышында гамәлгә ашырыла торган (кабул ителгән) гамәлләрне (гамәл кылмауны) һәм карарларны югары торучы дәүләт хакимияте органнарына шикаять кылу юлы белән дә, гамәлгә ашырыла.

**5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе**

5.1. Гариза бирүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган Идарә, Идарә вазыйфаи заты яисә Идарә дәүләт граждан хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Идарәгә шикаять белдерергә хокуклы.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү сәбәпле Идарә җитәкчесе тарафыннан кабул ителгән карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелә.

5.2. Гариза бирүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатьне теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләрне башкару таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны гариза бирүчедән кабул итеп алудан баш тарту очрагында;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту очрагында, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Идарәнең, аның вазыйфаи затының дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гариза бирүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять Идарәгә язмача рәвештә кәгазьдә яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта буенча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Идарәнең рәсми сайты, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның атамасы, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки дәүләт граждан хезмәткәренең исеме;

гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турындагы белешмәләр, гариза бирүче – юридик затның урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки дәүләт граждан хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

гариза бирүченең дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның, дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт граждан хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезли торган дәлилләр.

5.5. Гариза бирүче тарафыннан аның дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьләрне карау вакыты – аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә һәм Идарәнең, Идарә вазыйфаи затының гариза бирүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, гариза бирүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча гариза бирүчегә язмача яисә, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, әлеге пунктта күрсәтелгән гариза бирүчегә җавапта дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба гариза бирүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, әлеге пунктта күрсәтелгән гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.10. Шикаятьне карап тикшерү барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе тарафыннан апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

**Апостиль куеп, таныклана торган документка аерым кәгазь битен тегеп кую үрнәге**

Беренче ягы

APOSTILLE * АПОСТИЛЬ
(CONVENTION DE LA HAYE DU 5 OCTOBRE 1961 –
1961 елның 5 октябрендәге ГААГА КОНВЕНЦИЯСЕ)

1. Россия Федерациясе

Әлеге рәсми документ

2. ______________________________ тарафыннан имзаланды
(фамилия)

3. ______________________________________________________________________
__________________________________________сыйфатында катнаша.
(вазыйфа)

4. ____________________________________________________________________
____________________________________ мөһере/штампы белән беркетелде
(учреждениенең рәсми атамасы)

ТАНЫКЛАНДЫ

5. ________________ шәһәрендә 6. _______________
(дата саннар белән)

7. ______________________________________________________________________
(шәхеснең фамилиясе, вазыйфасы)

________________________________________________________________________
(таныклаучы орган исеме)

8. № белән

9. Мөһер урыны 10. Имза

_____________ _______________

Икенче ягы

Мөһер

__________ кәгазь битенә саннар сугылды, шнур белән тегелде һәм мөһер белән беркетелде

__________________________________
(дата һәм апостиль куйган затның имзасы)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе тарафыннан апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

киңәш ителә торган рәвеше

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенә
кемнән ________________________________
фамилиясе, исеме, атасының исеме
________________________ адресы буенча яши
________________________________________
шәхес таныклаучы документның
сериясе ______________ №_____________________
____________________ тарафыннан бирелгән

**ГАРИЗА**

_____________________________________________________________________
(документның төре, сериясе, номеры, бирелгән датасы)

таныклыкта/белешмәдә/ «апостиль» штампын кую турында сорыйм

_____________________________________ тарафыннан бирелде.
документны биргән ГХАТ органы исеме
____________________________________________ карата рәсмиләштерелгән.
документ рәсмиләштерелгән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме
_________________________________________ илдә куелган.

Документның әзер булуы турында миңа түбәндәгечә хәбәр итүне сорыйм
_________________________________________________________________
(хәбәр итү ысулы)

________________________ (_____________________________________).
(дата) (имза) (тулы имза)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе тарафыннан апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

**Гаризаларны теркәү**
**ЖУРНАЛЫ**

| т/с | Гаризаны кабул итеп алу датасы | Гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме, адресы | Мөрәҗәгать-нең кыскача эчтәлеге | Мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәсе | Башкаручының имзасы | Гариза бирүче-нең имзасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе тарафыннан апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

# АПОСТИЛЬЛӘР РЕЕСТРЫ

| Т/с | Апостиль кую датасы | Апостиль куела торган документның исеме, документка кул куйган затның фамилиясе, инициаллары һәм вазыйфасы | Үзенә карата документ төзелгән затның (затларның) фамилиясе, исеме, атасының исеме | Документ тапшырган затның имзасы |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе тарафыннан апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенә
кемнән ________________________________________
фамилиясе, исеме, атасының исеме
_______________ адресы буенча яши
____________________________________________
шәхес таныклаучы документ
сериясе ____________ №___________________
______________________ тарафыннан бирелгән

**Техник хата төзәтү турында**
**ГАРИЗА**

_____________________________________________________________________ апостиль
(гражданлык хәле актларын теркәү турында бирелгән документ)

куйганда җибәрелгән техник хата турында хәбәр итәм.
____________________________________________________________дип күрсәтелгән.

Дөрес белешмәләр:
________________________________________________________________________

Техник хатаны төзәтүегезне һәм дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне үтенәм.

Түбәндәге документларны терким:
1.
2.
Документның әзер булуы турында миңа түбәндәгечә хәбәр итүне сорыйм
________________________________________________________________________
(хәбәр итү ысулы)

__________________________ (_____________________________________________)
(дата) (имза) (тулы имза)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе тарафыннан апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмәлек)

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе тарафыннан апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы органнарның һәм вазыйфаи затларның һәм дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тотучы органнарның һәм вазыйфаи затларның реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсе**

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Идарә җитәкчесе | (843) 293-14-89 | Gulshat.Nigmatullina@tatar.ru |
| Идарә җитәкчесе урынбасары | (843) 293-01-57 | A.Renat@tatar.ru |
| Бүлек җитәкчесе | (843) 293-33-47 | Elza.Safiullina@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе җитәкчесе | (843) 264-77-29 | pisma@tatar.ru |